КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 май г.Казань № 628

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хуҗалык эшчәнлеге нигезләре турындагы нигезләмәне раслау һәм мәдәният һәм сәнгать оешмаларын финанслау турында» 1996 ел, 27 апрель, 345 нче карарының үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан дәүләт циркының Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары юрисдикциясенә күчүе турында» 1992 ел, 27 апрель, 250 нче карарына, преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасын һәм Казан дәүләт циркы коллективын алга таба икътисадый һәм социаль үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татаркино» дәүләт учреждениесе турында» 2006 ел, 3 февраль, 36 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 17 май, 253 нче, 2009 ел, 8 май, 296 нчы, 2010 ел, 31 август, 685 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «дәүләт учреждениесе турында» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе турында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татаркино» дәүләт учреждениесе» сүзләрен «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татаркино» дәүләт учреждениесе» сүзләрен «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктның дүртенче абзацында «Татаркино» дәүләт учреждениесе» сүзләрен «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «Татаркино» дәүләт учреждениесе» сүзләрен «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктта «дәүләт учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Н.И.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» Татарстан Республикасының урта һөнәри белем дәүләт автоном мәгариф учреждениесен төзү турында» 2007 ел, 15 октябрь, 563 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Н.И.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» (техникум) һөнәри белем дәүләт автоном мәгариф учреждениесен төзү турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Н.И.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» Татарстан Республикасының урта һөнәри белем дәүләт автоном учреждениесе коллективының һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының гамәлдәге «Н.И.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» дәүләт учреждениесе төрен үзгәртү юлы белән «Н.И.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (техникум) (алга таба – сәнгать училищесы) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гамәлгә куючы биремен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт заданиесен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән расланган Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт заданиесен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру турында нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ф.З.Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллияте» Татарстан Республикасының урта һөнәри белем дәүләт автоном мәгариф учреждениесен төзү турында» 2007 ел, 07 ноябрь, 603 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ф.З.Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Ф.З.Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллияте» Татарстан Республикасының урта һөнәри белем дәүләт автоном учреждениесе коллективының һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының гамәлдәге «Ф.З.Яруллин

исемендәге Әлмәт музыка көллияте» дәүләт учреждениесе төрен үзгәртү юлы белән «Ф.З.Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба – музыка көллияте) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гамәлгә куючы биремен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт заданиесен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән расланган Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт заданиесен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру турында нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гамәлдәге дәүләт учреждениесе төрен үзгәртү юлы белән «Чаллы сәнгать көллияте» Татарстан Республикасы урта һөнәри белем дәүләт автоном мәгариф учреждениесе төзү турында» 2007 ел, 07 ноябрь, 612 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чаллы сәнгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Чаллы сәнгать көллияте» Татарстан Республикасының урта һөнәри белем дәүләт автоном учреждениесе коллективының һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының гамәлдәге «Чаллы сәнгать көллияте» урта һөнәри белем дәүләт автоном мәгариф учреждениесе дәүләт учреждениесе төрен үзгәртү юлы белән «Чаллы сәнгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба – сәнгать көллияте) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гамәлгә куючы биремен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт заданиесен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән расланган Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт заданиесен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру турында нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә».

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гамәлдәге дәүләт учреждениесе төрен үзгәртү юлы белән «Алабуга мәдәният училищесы» Татарстан Республикасы урта һөнәри белем дәүләт автоном мәгариф учреждениесе төзү турында» 2007 ел, 07 ноябрь, 618 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 октябрь, 1015 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте» Татарстан Республикасының урта һөнәри белем дәүләт автоном учреждениесе коллективының һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының гамәлдәге «Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте» урта һөнәри белем дәүләт автоном мәгариф учреждениесе дәүләт учреждениесе төрен үзгәртү юлы белән «Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба - мәдәният училищесы) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.».

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы» имидж сурәте (бренды) («Татарстан мирасы» бренды) концепциясе турында» 2014 ел, 19 декабрь, 1004 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 апрель, 304 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән «Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы» имидж сурәте (бренды) («Татарстан мирасы» бренды) концепциясен расларга.

2. «Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы» имидж сурәте (бренды) («Татарстан мирасы» бренды) концепциясен гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы» брендын («Татарстан мирасы» брендын) гамәлгә кертү буенча эшче төркем төзергә һәм аның карарга теркәлгән составын расларга.»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга 1 нче кушымтаның нумерация баш исемендә «Карарга 1 нче кушымта» сүзләрен «Карар белән расланган» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1087 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 17 июль, 572 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 796 нчы, 2022 ел, 2 сентябрь, 945 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе бирү буенча конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Мөхәммәтҗанов Рәүфәл Сабир улы вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты»;

Тажетдинов Ринат Арифҗан улы вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе актеры, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы халык артисты».

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 25 май, 298 нче;

2018 ел, 21 май, 384 нче; 2019 ел, 25 гыйнвар, 38 нче; 2020 ел, 12 март, 187 нче; 2020 ел, 21 сентябрь, 850 нче; 2021 ел, 15 февраль, 81 нче; 2021 ел, 21 июль, 636 нчы; 2021 ел, 23 октябрь, 998 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 945 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе буенча комитет составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Глухова Лариса Юрьевна вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгын (килешү буенча)»;

Александровская Ирина Алексеевна вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы советы рәисе урынбасары, Казан шәһәре Совет районының «93 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча)»;

Комитет составыннан А.М.Терентьевны чыгарырга;

Комитет составына Мөхәрләмов Руслан Роберт улын - Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасарын, Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты җитәкчесен (килешү буенча).

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын раслау турында» 2020 ел, 17 февраль, 121 нче карары белән расланган Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына, Һашимова Нурия Миңнәхмәт кызы вазыйфасы исемендә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында» 2021 ел, 16 апрель, 252 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 24 декабрь, 1412 нче, 2023 ел, 1 март, 193 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

унынчы абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында нигезләмәдә:

исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Рәисенең «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә гамәлгә кую турында» 2021 елның 27 гыйнварындагы ПУ-60 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы бюджет һәм автоном мәдәният учреждениеләренә (алга таба - учреждениеләр) субсидияләр рәвешендә Татарстан Республикасы Президентының грантларын (алга таба - грантлар) бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели.»;

әлеге карар белән расланган Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантлары күләме исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү стратегиясен раслау турында» 2021 ел, 17 май, 344 нче карары белән расланган 2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү стратегиясенә, V бүлекнең тугызынчы абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

13. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәдәният һәм сәнгать оешмаларының хуҗалык эшчәнлеге нигезләре һәм финанслау турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1996 ел, 27 апрель, 345 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 19 декабрь, 1004 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 23 май, 628 нче
карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы» имидж сурәте (бренды) («Татарстан мирасы» бренды) концепциясен гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы» брендын («Татарстан мирасы» брендын) гамәлгә кертү буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Арсланов Азат Мөхәммәтгали улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы урынбасары |
| Әсәдуллина Алсу Мөнип кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Балтусова Олеся Александровна | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Гафаров Рөстәм Гыйльфан улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Денисов Максим Сергеевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Камалетдинова Гөлия Фидаил кызы | «Татарстанның мәдәни мирас үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе урынбасары |

| | |
|---|---|
| Ларионова Татьяна Петровна | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча) |
| Лулаков Денис Владиславович | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары |
| Миргалимов Илдар Флүс улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм масса-күләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары |
| Мифтахова Алсу Равил кызы | «Татарстан Республикасының Мәдәният өлкәсендә инновацияләрне кертү һәм традицияләрне саклап калу буенча ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Низамов Рәшит Корбангали улы | «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Рәхимов Илнур Сөләйман улы | «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Судакова Арина Алексеевна | Evolution креатив агентлык җитәкчесе (килешү буенча) |
| Халәпов Альберт Айрат улы | «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесе башкарма директоры. |